| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 16 нчы сентябре Олы Кайбыч авылы № 16

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Олы Кайбыч авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Олы Кайбыч авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Олы Кайбыч авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:*

- Иске Чәчкаб авылындагы күлне ремонтлау, чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- паркны төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

- җәяүлеләр күперен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу.

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:*

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту*:

- зиратларны чистарту һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту һәм моның өчен материаллар сатып алу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында һәм Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://bkaybic-kaybici.tatarstan.ru.

3. Карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге башлыгы — А.И. Рәхмәтуллин

Совет Большекайбицкого сельского поселения
Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы
1621000502